ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты составына һәм Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Коробченко Олег Владимировичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты составыннан чыгарырга.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетын сайлау турында» 2019 елның 20 сентябрендәге 15-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының икенче абзацында (2020 елның 20 февралендәге 304-VI ДС номерлы һәм 2021 елның 23 апрелендәге 944-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) «12» санын «11» санына алмаштырырга.

3. «Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясен төзү турында» 2019 елның 20 сентябрендәге 32-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген

тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составыннан Коробченко Олег Владимировичны чыгарырга;

б) Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Җиһаншин Азат Илдус улын кертергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 15 июне
№ 1459-VI ДС